**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нчейорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

КАРАР
от 10.10.2018 г

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-250

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспрты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын раслау турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законы һәм “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында яшәүчеләргә траспорт хезмәте күрсәтү һәм пассажирлар йөртү иминлеген арттыру максатыннан

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге нигезләмәнең кушымтасы нигезендә (кушымта бирелә) Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспорты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын расларга .

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлегенә:

2.1. Актаныш муниципаль районы территориясе буенча автомобиль транспорты белән даими рәвештә пассажирлар һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары расланган реестры нигезендә пассажирлар һәм багаж ташуны тәэмин итәргә.

2.2. Актаныш муниципаль районы территориясе буенча пассажир транспорты маршрутлары, автобус хәрәкәте графикларын билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм расларга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru. адресында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.И Гариповка йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе
урынбасары вазифаларын башкаручы А.И.Тимиров